СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17.08.2021 Әгерҗе шәһәре № 11-11

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру хокукына торглар үткәрү рәвешен билгеләү турында

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы карары, «Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 5 өлеше, «Татарстан Республикасы “Әгерҗе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Әгерҗе муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру хокукына (муниципаль милектә булган яисә дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлегендә реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамә төзү хокукына, шулай ук муниципаль милектәге бинада яисә башка күчемсез мөлкәттә) торглар үткәрү Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан, Россия Федерациясе законнары нигезендә ачык аукцион рәвешендә, электрон рәвештә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Татмедиа» АҖ филиалының Әгерҗе районы «Әгерҗе хәбәрләре» («Агрызские вести») газетасында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре, экология, табигый ресурслар һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет рәисе

А.Р. Вәлиев